| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.03.2021 Казан ш. № 129-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгының 03.02.2020 № 62-пр боерыгы белән расланган Торакларны Татарстан Республикасы махсус торак фонды составына кертү һәм аның составыннан чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүенә бәйле рәвештә боерам:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Торакларны Татарстан Республикасы махсус торак фонды составына кертү һәм аның составыннан чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 03.02.2020 № 62-пр боерыгы белән расланган Торакларны Татарстан Республикасы махсус торак фонды составына кертү һәм аның составыннан чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 15.12.2020 № 758-пр боерыгы белән кертелә торган үзгәрешләр белән) кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
04.03.2021 № 129-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Торакларны Татарстан Республикасы махсус торак фонды составына кертү һәм аның составыннан чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 03.02.2020 № 62-пр боерыгы белән расланган Торакларны Татарстан Республикасы махсус торак фонды составына кертү һәм аның составыннан чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган
үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торакка теркәлгән гражданнарың шәхесен раслаучы документларныд күчермәләре (14 яше тулган һәм аннан олырак булган гаилә әгъзаларының паспортлары (шәхесне раслаучы бүтән документлар)), 14 яше тулмаган гаилә әгъзаларының туу турында таныклык күчермәләре, аларның туу турында таныклыгы чит дәүләтләрнең компетентлы органнары тарафыннан тапшырылган икән, әлеге таныклыкларның нотариаль расланган тәрҗемәләре.»;

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Милек хокукын яисә торакка хуҗалык идарәсе яки оператив идарә хокукын раслаган документ.

Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысасында түбәндәгеләр алына:

торак турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (алга таба - ЕГРН), Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль идарәсеннән (алга таба – ТР буенча Росреестр);

фатир биләүченең гаиләсендәге 14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган балаларның тууы дәүләти регистрацияләнүе турында белешмә, вәкаләтле органнардан;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан (алга таба – РФ ПФ) инвалидлык турында белешмә (инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык

билгеләнүен раслаучы белешмә; инвалидны, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы), мәгълүмат «Инвалидларның Федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмати системасында (ФГИС ФРИ) булырга тиеш, гражданин (торакны яллаучы) инвалид булса яки аның гаиләсе составында инвалид булса (хезмәт торагын махсус торак фондыннан чыгарган очракларда);

РФ ХК 66[1] статьясы буенча билгеләнгән тәртиптә РФ ПФнан яки эш бирүчедән соңгы эш урыны буенча хезмәт эшчәнлеге турында белешмә (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге периодка).

Гариза бирүче ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысасында алына торган документларны үз инициативасы белән дә тапшыра ала, шул исәптән, мөмкинлек булса, электрон формада да.

Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга сәбәп булып тормый.

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә килеп чыккан мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирүне, гамәлләр башкару таләп итү;

Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары карамагында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм (яисә) оешмаларда булган документлар һәм мәгълүмат бирелүне, шулай ук, аларны алу өчен түләү кертелүен раслаган докуемнтларны сорау. № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар искәрмә булып тора;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешендә 4 пунктында күрсәтелгән очраклар искәрмә булып тора»;

3 пунктның 3.4.1 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече гаризаны һәм документларны эш башкару бүлегеннән алганнан соң ведомостволара электрон арадашлык системасы аша электрон формада запрос юллый:

торак турында ЕГРНнан өземтә бирүне, ТР буенча Росреестрдан;

фатир биләүченең гаиләсендәге 14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган балаларның тууы дәүләти регистрацияләнүе турында белешмә бирү турында, вәкаләтле органнардан;

РФ ПФнан инвалидлык турында белешмә бирүне (инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык билгеләнүен раслаучы белешмә; инвалидны, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы), мәгълүмат «Инвалидларның Федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмати системасында (ФГИС ФРИ) булырга тиеш, гражданин (торакны яллаучы) инвалид булса яки аның гаиләсе составында инвалид булса (хезмәт торагын махсус торак фондыннан чыгарган очракларда);

РФ ХК 66[1] статьясы буенча билгеләнгән тәртиптә хезмәт эшчәнлеге турында белешмә (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге периодка), РФ ПФнан яки соңгы эш урыны буенча эш бирүчедән.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.»;

Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Торакны Татарстан Республикасының махсус торак фонды составына кертү һәм аның составыннан чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

______________________________________
Ф.И.ӘИ

**Торакны (торакларны) Татарстан Республикасының махсус торак фонды составыннан чыгару турында гариза**
(киңәш ителгән форма)

Татарстан Республикасы, _______________ шәһәре, ________________урамы, № ______ йорт, корпус № (литер) ____________, фатир/бүлмә (фатирлар/бүлмәләр) № _______________, адресы буенча урнашкан оператив идарә (хуҗалык идарәсе) хокукында ____________________ ____________________________________ беркетелгән торакны (торакларны)
юридик зат атамасы

__________________________ нигезендә,

-хезмәт торагына (хезмәт торакларына);

- тулай торактагы торак бүлмәсенә (торак бүлмәләренә)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының _________№_____ карары нигезендә Татарстан Республикасының махсус фонды составыннан чыгаруны сорый.

Беркетелгән документлар:

1. _______________________________________________________
2. _______________________________________________________
3. _______________________________________________________
4. _______________________________________________________

Җитәкче:____ ______________________/_______________________/

Элемтә өчен телефон _____________

/гаризаның кире ягы/

Махсус фонды торагында теркәлгән фатир биләүченең гавилә әгъзалары составы

| № п/п | Ф.И.ӘИ. (тулысы белән) РФ коралны көчләрендә хәрби хезмәттә, командировкада, ирегеннән мәхрүм итү урыннарында һ.б. булучыларын да исәпкә алып | Туган көне (көне, ае, елы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт, туу турында таныклык мәгълүматы (серия, номер, кем һәм кайчан биргән, бүлекчә коды) | Теркәлгән датасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | | | Торак биләүче | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |

Җитәкче:____ ________________________/_________________________/

МП».